Ел саен 4 ноябрьдә илебез Халыклар бердәмлеге конен билгеләп vткәрә. Россия Федерациясе территориясендә яшәvче 190 дан артык халыкны уртак тарих, хәтер һәм традицияләргә тугрылык берләштерә.

Бәйрәм унаеннан тантаналы чаралар, мастер – класслар, уеннар, шоулар һәм татлы бvләкләр - менә шулай Халыклар бердәмлеге конен Рузаевкада бәйрәм иттеләр.

Унсигез ел рәттән Рузаевка районында уникаль «Татлы шатлык» акциясен vткәрәләр. А.В.Ухтомский исемендәге мәдәният vзәгенә Рузаевка администрациясе ярдәме белән оештырылган чараларда йозләрчә жыелган бала бу

кон алар очен берләшv һәм шатлык коненә әверелгән. Аларнын бәхетле йозләрен кvрv бик кvнелле! Безне кочлерәк итә торган бердәмлек шул инде. Ул бер-беребезгә ярдәм итеп, барысын да булдыра алуыбызны искә тошерә. Без - бер зур гаилә!

Халыклар бердәмлеге конен бәйрәм итv кысаларында Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбе тәрбия буенча директор кинәшчесе Альфия Фатих кызы Муртазина «Россия - гаиләләр гаиләсе» Ботенроссия ак-циясе кысаларында «Мәдәниятләр марафоны» дигән интерактив викторина оештырды.

«Мәдәниятләр марафоны» интерактив викторинасы балаларга vзлә-ренен белемнәрен һәм мәдәниятләрнен бердәмлеге һәм кvпторлелеге темасына ижади якын килvләрен кvрсәтергә момкинлек биргән. Шулай ук мәктәп активистлары «Без торле, әмма без бердәм» дигән плакат ясаганнар. Ул кvпмилләтле Россиядә бердәмлек һәм татулыкнын визуаль символына әверелгән.

Наилә НАСЫРОВА